ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**
28.06.2024 № 596

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2023-2025 елларга Биектау муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 17 апрелендәге 488 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2023-2025 елларга Биектау муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 17 апрелендәге 488 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасының 2 бүлегенең 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар дип, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законда каралган формаларда (дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, сәяси партияләр булган иҗтимагый берләшмәләрдән, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) төзелгән һәм социаль проблемаларны хәл итүгә, Россия Федерациясендә гражданлык җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашырган коммерциячел булмаган оешмалар, шулай ук «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 31_1 статьясында каралган эшчәнлек төрләре танылa».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин